ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТҮКЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423732, Түке авылы,
Ленин ур., 61/2 нче йорт.
Тел.3-44-61

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ТЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГ
РАЙОНА

423732, с. Тюково,
ул. Ленина, дом 61/2 ,
Тел. 3-44-61

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Түке авыл җирлеге составына керүче Чәчер авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

19 декабрь 2024 ел №26

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 ноябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Түке авыл җирлегенең Чәчер авылында 2024 елның 28 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: “2025 елда Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Чәчер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә үзара салым кертүгә риза буласызмы? - дигән сорау буенча, 1 төркем инвалидлардан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, мобилизацияләнгән гражданнардан, ирекле һәм хәрби хезмәткәрләрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итә торган башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү системаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су үткәрү челтәрен ремонтлау);
2. торак пункт территориясен төзекләндерү (ташландык җир кишәрлекләрендә агачларны һәм куакларны кисү, урам юллары кырыйларында үлән чаптыру);
3. Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка мәйданчыкларны ремонтлау (урам яктырткычларын тоту һәм алмаштыру);
4. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау).

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә: